**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

# Об образовании Республиканского организационного комитета по подготовке и проведению ежегодного форума «Международная строительная неделя БРИКС»

В целях организации взаимодействия органов государственной власти, организаций в сфере строительства и жилищно-коммунального хозяйства, общественных объединений предпринимателей и иных организаций при подготовке и проведении ежегодного форума «Международная строительная неделя БРИКС» **постановляю**:

1. Образовать Республиканский организационный комитет по подготовке и проведению ежегодного форума «Международная строительная неделя БРИКС».

2. Утвердить Положение о Республиканском организационном комитете по подготовке и проведению ежегодного форума «Международная строительная неделя БРИКС» (приложение № 1) и его состав (приложение № 2).

3. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Раис**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казань, Кремль
02 июля 2026 года
№ 539

Приложение № 1
к Указу Раиса
Республики Татарстан

от «02» июля 2026 года

№ 539

**ПОЛОЖЕНИЕ**
**о Республиканском организационном комитете по подготовке и проведению ежегодного форума «Международная строительная неделя БРИКС»**

## I. Общие положения

1. Республиканский организационный комитет по подготовке и проведению ежегодного форума «Международная строительная неделя БРИКС» (далее соответственно – Организационный комитет, Форум) является коллегиальным органом, образованным в целях организации взаимодействия органов государственной власти, организаций в сфере строительства и жилищно-коммунального хозяйства, общественных объединений предпринимателей и иных организаций при подготовке и проведении Форума.

2. Организационный комитет в своей деятельности руководствуется Конституцией Российской Федерации, федеральными конституционными законами, федеральными законами, иными нормативными правовыми актами Российской Федерации, Конституцией Республики Татарстан, законами Республики Татарстан и иными нормативными правовыми актами Республики Татарстан, а также настоящим Положением.

## II. Основные задачи Организационного комитета

3. Основными задачами Организационного комитета являются:

а) разработка и утверждение деловой программы Форума, а также плана мероприятий по подготовке и проведению Форума (далее – План);

б) анализ хода реализации Плана, программ и отдельных мероприятий, связанных с подготовкой и проведением Форума, обеспечение контроля за их выполнением и целевым использованием финансовых средств, выделенных на его реализацию;

в) разработка предложений по организации взаимодействия органов государственной власти, организаций в сфере строительства и жилищно-коммунального хозяйства, общественных объединений предпринимателей и иных организаций в процессе реализации принятых Организационным комитетом решений и оценка их эффективности;

г) организация взаимодействия органов государственной власти, организаций в сфере строительства и жилищно-коммунального хозяйства, общественных объединений предпринимателей и иных организаций при решении задач, связанных с выполнением Плана.

4. Организационный комитет в целях реализации стоящих перед ним задач имеет право:

а) запрашивать и получать в соответствии с законодательством от органов государственной власти, организаций в сфере строительства и жилищно-коммунального хозяйства, общественных объединений предпринимателей и иных организаций информационные материалы по вопросам, относящимся к компетенции Организационного комитета;

б) создавать в установленном порядке рабочие группы для решения вопросов, относящихся к компетенции Организационного комитета;

в) приглашать в установленном порядке на свои заседания руководителей и иных представителей органов государственной власти, организаций в сфере строительства и жилищно-коммунального хозяйства, а также других организаций и заинтересованных лиц.

## III. Состав Организационного комитета

5. Состав Организационного комитета утверждается Раисом Республики Татарстан.

6. В состав Организационного комитета входят председатель, сопредседатель, заместитель председателя, секретарь и иные члены Организационного комитета, которые принимают участие в его работе на общественных началах.

7. Председатель Организационного комитета:

а) руководит работой Организационного комитета, определяет перечень, сроки и порядок рассмотрения вопросов на заседаниях Организационного комитета;

б) распределяет полномочия (обязанности) между сопредседателем, заместителем председателя и членами Организационного комитета;

в) определяет и утверждает повестку дня, дату, время и место проведения заседаний Организационного комитета;

г) подписывает протоколы заседаний и другие документы Организационного комитета.

8. Сопредседатель Организационного комитета:

а) участвует в руководстве работой Организационного комитета;

б) выполняет полномочия (обязанности) председателя Организационного комитета в его отсутствие;

в) вправе вносить предложения по повестке дня заседаний;

г) осуществляет иные полномочия (обязанности) по поручению председателя Организационного комитета.

9. Заместитель председателя Организационного комитета:

а) выполняет отдельные поручения председателя Организационного комитета;

б) председательствует на заседаниях Организационного комитета в случае отсутствия председателя Организационного комитета и сопредседателя Организационного комитета;

в) координирует работу рабочих групп.

10. Секретарь Организационного комитета:

а) участвует лично в заседаниях Организационного комитета;

б) уведомляет членов Организационного комитета о месте, дате, времени проведения заседания не менее чем за пять дней до дня проведения заседания, рассылает повестку дня заседания;

в) обеспечивает подготовку заседания Организационного комитета;

г) осуществляет подготовку протоколов заседаний и других документов Организационного комитета.

11. Члены Организационного комитета:

а) участвуют лично в заседаниях Организационного комитета;

б) выносят на обсуждение предложения по вопросам, находящимся в компетенции Организационного комитета;

в) осуществляют иные мероприятия по подготовке, исполнению решений Организационного комитета.

## IV. Заседания и решения Организационного комитета

12. Основной формой деятельности Организационного комитета являются заседания, которые могут быть организованы очно и (или) посредством видео-конференц-связи.

13. Заседания Организационного комитета проводятся по мере необходимости.

14. Заседания Организационного комитета ведет председатель Организационного комитета, а в его отсутствие – сопредседатель Организационного комитета. При отсутствии председателя Организационного комитета и сопредседателя Организационного комитета – заместитель председателя Организационного комитета.

15. Заседание Организационного комитета считается правомочным, если в нем принимают участие более половины его членов. Решение Организационного комитета считается принятым, если за него проголосовало не менее половины членов Организационного комитета, присутствующих на заседании. При равенстве голосов голос председательствующего является решающим.

По результатам рассмотрения вопросов повестки дня и голосования на заседании Организационного комитета принимаются решения, которые оформляются протоколом. Протокол заседания Организационного комитета подписывается председательствующим.

16. Решения, принимаемые Организационным комитетом, доводятся до заинтересованных органов государственной власти, организаций в сфере строительства и жилищно-коммунального хозяйства, общественных объединений предпринимателей, иных заинтересованных лиц для руководства при осуществлении текущей деятельности.

## V. Обеспечение деятельности Организационного комитета

17. Материально-техническое, документационное, информационное и иное обеспечение деятельности Организационного комитета осуществляется Кабинетом Министров Республики Татарстан во взаимодействии с Союзом «Торгово-промышленная палата Республики Татарстан».

---

Приложение № 2
к Указу Раиса
Республики Татарстан

от «02» июля 2026 года

№ 539

**СОСТАВ**
**Республиканского организационного комитета по подготовке и проведению ежегодного форума «Международная строительная неделя БРИКС»**

| | |
|---|---|
| Файзуллин Ирек Энварович | Министр строительства и жилищно-коммунального хозяйства Российской Федерации, председатель Организационного комитета (по согласованию) |
| Минниханов Рустам Нургалиевич | Раис Республики Татарстан, сопредседатель Организационного комитета |
| Песошин Алексей Валерьевич | Премьер-министр Республики Татарстан, заместитель председателя Организационного комитета |
| Айзатуллин Марат Мансурович | министр строительства, архитектуры и жилищно-коммунального хозяйства Республики Татарстан, секретарь Организационного комитета |
| Абубакирова Элеонора Халиловна | заместитель министра строительства, архитектуры и жилищно-коммунального хозяйства Республики Татарстан |
| Агеев Шамиль Рахимович | председатель Союза «Торгово-промышленная палата Республики Татарстан» (по согласованию) |
| Аглиуллин Фаниль Анварович | министр земельных и имущественных отношений Республики Татарстан |

| | |
|---|---|
| Ахматов Марат Камчыевич | начальник отдела промышленности Аппарата Кабинета Министров Республики Татарстан |
| Ахметзянов Айдар Ильгизович | руководитель департамента развития территорий Министерства строительства, архитектуры и жилищно-коммунального хозяйства Республики Татарстан |
| Аюпова Ирада Хафизяновна | министр культуры Республики Татарстан |
| Бакиров Газинур Тальгатович | помощник Раиса Республики Татарстан |
| Балтусова Олеся Александровна | помощник Раиса Республики Татарстан |
| Галимбеков Айрат Ринатович | генеральный директор государственного унитарного предприятия Республики Татарстан «Татлизинг» (по согласованию) |
| Гафаров Шамиль Хамитович | заместитель Премьер-министра Республики Татарстан – Руководитель Аппарата Кабинета Министров Республики Татарстан |
| Григорьев Олег Дмитриевич | директор государственного бюджетного учреждения «Институт пространственного планирования Республики Татарстан» (по согласованию) |
| Ересько Алексей Васильевич | заместитель Министра строительства и жилищно-коммунального хозяйства Российской Федерации (по согласованию) |
| Зиганшин Азат Ильдусович | министр экологии и природных ресурсов Республики Татарстан |
| Иванов Сергей Евгеньевич | председатель Государственного комитета Республики Татарстан по туризму |
| Коробченко Олег Владимирович | заместитель Премьер-министра Республики Татарстан – министр промышленности и торговли Республики Татарстан |

| | |
|---|---|
| Кузьмина Александра Александровна | председатель Совета главных архитекторов субъектов Российской Федерации и муниципальных образований им. А.В. Кузьмина, главный архитектор Московской области (по согласованию) |
| Леонов Владимир Александрович | министр спорта Республики Татарстан |
| Ломакин Александр Николаевич | первый заместитель Министра строительства и жилищно-коммунального хозяйства Российской Федерации (по согласованию) |
| Мерзакреев Рустэм Рауфович | помощник Раиса Республики Татарстан |
| Миннегалиев Роберт Хамитович | генеральный директор автономной некоммерческой организации «Центр развития и поддержки конгрессно-выставочных, культурных, зрелищно-развлекательных, спортивно-массовых и социально ориентированных мероприятий «Казань Экспо» (по согласованию) |
| Минуллина Талия Ильгизовна | руководитель Агентства инвестиционного развития Республики Татарстан |
| Михайлик Константин Александрович | заместитель Министра строительства и жилищно-коммунального хозяйства Российской Федерации (по согласованию) |
| Музыченко Сергей Григорьевич | заместитель Министра строительства и жилищно-коммунального хозяйства Российской Федерации (по согласованию) |
| Муценек Юрий Петрович | статс-секретарь – заместитель Министра строительства и жилищно-коммунального хозяйства Российской Федерации (по согласованию) |
| Назмеев Вали Рифарович | начальник Инспекции государственного строительного надзора Республики Татарстан |

| | |
|---|---|
| Насибуллин Назиль Наилович | помощник Премьер-министра Республики Татарстан по внешнеэкономической деятельности |
| Нафигин Альберт Ильдарович | помощник Раиса Республики Татарстан |
| Низамов Рашит Курбангалиевич | ректор федерального государственного бюджетного образовательного учреждения высшего образования «Казанский государственный архитектурно-строительный университет» (по согласованию) |
| Савельев Игорь Леонидович | заместитель Руководителя Администрации Раиса Республики Татарстан – руководитель Экспертного департамента Раиса Республики Татарстан |
| Салимгараев Айдар Саитгараевич | руководитель Республиканского агентства по печати и массовым коммуникациям «Татмедиа» |
| Сафин Ленар Ринатович | ректор федерального государственного автономного образовательного учреждения высшего образования «Казанский (Приволжский) федеральный университет» (по согласованию) |
| Сафиуллина Дина Ринатовна | директор федерального автономного учреждения «Проектная дирекция Министерства строительства и жилищно-коммунального хозяйства Российской Федерации» (по согласованию) |
| Сибгатуллин Ильдар Нурзадович | начальник Управления строительства, транспорта, жилищно-коммунального и дорожного хозяйств Аппарата Кабинета Министров Республики Татарстан |
| Стасишин Никита Евгеньевич | заместитель Министра строительства и жилищно-коммунального хозяйства Российской Федерации (по согласованию) |

| | |
|---|---|
| Шакиров Рафар Мирзанурович | директор государственного автономного учреждения «Управление государственной экспертизы и ценообразования Республики Татарстан по строительству и архитектуре» (по согласованию) |
| Шумаков Николай Иванович | президент Общероссийской творческой профессиональной общественной организации «Союз архитекторов России» (по согласованию) |

**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Ел саен үткәрелә торган «БРИКС халыкара төзелеш атнасы» форумын әзерләү һәм уздыру буенча республика оештыру комитеты төзү турында**

Дәүләт хакимияте органнарының, төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсе оешмаларының, эшкуарларның җәмәгать берләшмәләре һәм башка оешмаларның ел саен үткәрелә торган «БРИКС халыкара төзелеш атнасы» форумын әзерләүдә һәм уздыруда үзара хезмәттәшлеген оештыру максатларында **карар бирәм**:

1. Ел саен үткәрелә торган «БРИКС халыкара төзелеш атнасы» форумын әзерләү һәм уздыру буенча республика оештыру комитеты төзергә.

2. Ел саен үткәрелә торган «БРИКС халыкара төзелеш атнасы» форумын әзерләү һәм уздыру буенча республика оештыру комитеты турында нигезләмәне (1 нче кушымта) һәм комитетның составын (2 нче кушымта) расларга.

3. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ • АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2026 ел, 02 июль
№ 539

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2026 елның « 02 » июлендәге
539 номерлы Указына
1 нче кушымта

**Ел саен үткәрелә торган «БРИКС халыкара төзелеш атнасы» форумын әзерләү һәм уздыру буенча республика оештыру комитеты турында**
# НИГЕЗЛӘМӘ

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Ел саен үткәрелә торган «БРИКС халыкара төзелеш атнасы» форумын әзерләү һәм уздыру буенча республика оештыру комитеты (алга таба – Оештыру комитеты, Форум) дәүләт хакимияте органнарының, төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендәге оешмаларның, эшкуарларның җәмәгать берләшмәләренең һәм башка оешмаларның Форумны әзерләүдә һәм уздыруда үзара хезмәттәшлеген оештыру максатларында төзелгән коллегиаль орган булып тора.

2. Оештыру комитеты үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, федераль законнарга, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

## II. Оештыру комитетының төп бурычлары

3. Оештыру комитетының төп бурычлары түбәндәгеләр:

а) Форумның эшлекле программасын, шулай ук Форумны әзерләү һәм уздыру чаралары планын (алга таба – План) эшләү һәм раслау;

б) Форумны әзерләүгә һәм уздыруга бәйле Планны, программаларны һәм аерым чараларны гамәлгә ашыру барышына анализ, аларның үтәлешен һәм аны гамәлгә ашыруга бүлеп бирелгән финанс чараларыннан максатчан файдалануны тикшереп торуны тәэмин итү;

в) Оештыру комитеты кабул иткән карарларны гамәлгә ашыру барышында дәүләт хакимияте органнарының, төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендәге оешмаларның, эшкуарларның җәмәгать берләшмәләренең һәм башка оешмаларның үзара хезмәттәшлеген оештыру буенча тәкъдимнәр әзерләү һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү;

г) Планны үтәүгә бәйле бурычларны хәл иткәндә дәүләт хакимияте органнарының, төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендәге оешмаларның, эшкуарларның җәмәгать берләшмәләренең һәм башка оешмаларның үзара хезмәттәшлеген оештыру.

4. Оештыру комитеты үз алдында торган бурычларны гамәлгә ашыру максатларында түбәндәгеләргә хокуклы:

а) Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт хакимияте органнарыннан, төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендәге оешмалардан, эшкуарларның җәмәгать берләшмәләреннән һәм башка оешмалардан Оештыру комитеты компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча мәгълүмати материаллар соратып алырга;

б) Оештыру комитеты компетенциясенә караган мәсьәләләрне хәл итү юнәлешләре буенча билгеләнгән тәртиптә эш төркемнәре төзергә;

в) үз утырышларына билгеләнгән тәртиптә төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендәге оешмаларның, шулай ук башка оешмаларның һәм кызыксынган затларның җитәкчеләрен һәм башка вәкилләрен чакырырга.

## III. Оештыру комитеты составы

5. Оештыру комитеты составы Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан раслана.

6. Оештыру комитеты составына Оештыру комитеты эшендә җәмәгать башлангычларында катнашучы Оештыру комитеты рәисе, рәистәше, рәис урынбасары, секретаре һәм башка әгъзалары керә.

7. Оештыру комитеты рәисе:

а) Оештыру комитеты эшенә җитәкчелек итә, Оештыру комитеты утырышларындагы мәсьәләләр исемлеген, аларны карап тикшерү срокларын һәм тәртибен билгели;

б) Оештыру комитеты рәистәше, рәис урынбасары һәм әгъзалары арасында вәкаләтләрне (бурычларны) бүлә;

в) Оештыру комитеты утырышларының көн тәртибен, үткәрү датасын, вакытын һәм урынын билгели һәм раслый;

г) Оештыру комитеты утырышлары беркетмәләренә һәм башка документларына кул куя.

8. Оештыру комитеты рәистәше:

а) Оештыру комитеты эшенә җитәкчелек итүдә катнаша;

б) Оештыру комитеты рәисе эш урынында булмаганда, аның вәкаләтләрен (вазыйфаларын) башкара;

в) утырышларның көн тәртибе буенча тәкъдимнәр кертергә хокуклы;

г) Оештыру комитеты рәисе күрсәтмәсе буенча башка вәкаләтләрне (бурычларны) башкара.

9. Оештыру комитеты рәисе урынбасары:

а) Оештыру комитеты рәисенең аерым йөкләмәләрен үти;

б) Оештыру комитеты рәисе һәм Оештыру комитеты рәистәше булмаган очракта, Оештыру комитеты утырышларында рәислек итә;

в) эш төркемнәре эшен килештерә.

10. Оештыру комитеты секретаре:

а) Оештыру комитеты утырышларында шәхсән катнаша;

б) Оештыру комитеты әгъзаларына утырыш уздыру көненә кимендә биш көн кала утырышны уздыру урыны, датасы, вакыты турында хәбәр итә, утырышның көн тәртибен юллый;

в) Оештыру комитеты утырышын әзерләүне тәэмин итә;

г) Оештыру комитеты утырышлары беркетмәләрен һәм башка документларын әзерли.

11. Оештыру комитеты әгъзалары:

а) Оештыру комитеты утырышларында шәхсән катнашалар;

б) Оештыру комитеты компетенциясендәге мәсьәләләр буенча тәкъдимнәрне фикер алышуга куялар;

в) Оештыру комитеты карарларын әзерләү, үтәү буенча башка чараларны гамәлгә ашыралар.

## IV. Оештыру комитеты утырышлары һәм карарлары

12. Оештыру комитеты эшчәнлегенең төп формасы – әгъзаларның турыдан-туры катнашуы рәвешендә һәм (яисә) видео-конференц-элемтә ярдәмендә оештырылырга мөмкин булган утырышлар.

13. Оештыру комитеты утырышлары кирәк булган саен уздырыла.

14. Оештыру комитеты утырышларын Оештыру комитеты рәисе, ә ул булмаганда Оештыру комитеты рәистәше, Оештыру комитеты рәисе һәм Оештыру комитеты рәистәше булмаганда, Оештыру комитеты рәистәше урынбасары алып бара.

15. Оештыру комитеты утырышында аның әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, ул эш йөртергә хокуклы дип санала. Оештыру комитеты карары, әгәр аны хуплап утырышта катнашучы Оештыру комитеты әгъзаларның кимендә яртысы тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала. Тавышлар саны тигез булганда, рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

Оештыру комитеты утырышында көн тәртибендәге мәсьәләләрне карап тикшерү һәм тавыш бирү нәтиҗәләре буенча беркетмә белән рәсмиләштерелә торган карарлар кабул ителә. Оештыру комитеты утырышы беркетмәсенә рәислек итүче кул куя.

16. Оештыру комитеты кабул итә торган карарлар агымдагы эшчәнлекне гамәлгә ашырганда җитәкчелек итү өчен кызыксынган дәүләт хакимияте органнарына, төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендәге оешмаларга, эшкуарларның җәмәгать берләшмәләренә, башка кызыксынган затларга җиткерелә.

## V. Оештыру комитеты эшчәнлеген тәэмин итү

17. Оештыру комитеты эшчәнлеген матди-техник яктан, документлар, мәгълүмат белән һәм башкача тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан «Татарстан Республикасы Сәүдә-сәнәгать палатасы» Берлеге белән бергәләп гамәлгә ашырыла.

---

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2026 елның «02» июлендәге
539 номерлы Указына
2 нче кушымта

**Ел саен үткәрелә торган «БРИКС халыкара төзелеш атнасы» форумын әзерләү һәм уздыру буенча республика оештыру комитеты**
**СОСТАВЫ**

| | |
|---|---|
| Фәйзуллин<br>Ирек Әнвәр улы | Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министры, Оештыру комитеты рәисе (килешү буенча) |
| Миңнеханов<br>Рөстәм Нургали улы | Татарстан Республикасы Рәисе, Оештыру комитеты рәистәше |
| Песошин<br>Алексей Валерьевич | Татарстан Республикасы Премьер-министры, Оештыру комитеты рәисе урынбасары |
| Айзатуллин<br>Марат Мансур улы | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры, Оештыру комитеты секретаре |
| Әбүбәкерова<br>Элеонора Хәлил кызы | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры урынбасары |
| Агиев<br>Шамил Рәхим улы | «Татарстан Республикасы Сәүдә-сәнәгать палатасы» Берлеге рәисе (килешү буенча) |
| Әгълиуллин<br>Фәнил Әнвәр улы | Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры |

| | |
|---|---|
| Әхмәтов<br>Марат Камчы улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының сәнәгать бүлеге башлыгы |
| Әхмәтҗанов<br>Айдар Илгиз улы | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының территорияләрне үстерү департаменты җитәкчесе |
| Әюпова<br>Ирада Хафизҗан кызы | Татарстан Республикасы мәдәният министры |
| Бакиров<br>Газинур Тәлгать улы | Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесе |
| Балтусова<br>Олеся Александровна | Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесе |
| Галимбәков<br>Айрат Ринат улы | Татарстан Республикасының «Татлизинг» дәүләт унитар предприятиесе генераль директоры (килешү буенча) |
| Гафаров<br>Шамил Хәмит улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесе |
| Григорьев<br>Олег Дмитриевич | «Татарстан Республикасының пространство планлаштыру институты» дәүләт бюджет учреждениесе директоры (килешү буенча) |
| Ересько<br>Алексей Васильевич | Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министры урынбасары (килешү буенча) |
| Җиһаншин<br>Азат Илдус улы | Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министры |
| Иванов<br>Сергей Евгеньевич | Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты рәисе |

| | |
|---|---|
| Коробченко<br>Олег Владимирович | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры |
| Кузьмина<br>Александра Александровна | Россия Федерациясе субъектлары һәм муниципаль берәмлекләре баш архитекторларының А.В. Кузьмин исемендәге советы рәисе, Мәскәү өлкәсе баш архитекторы (килешү буенча) |
| Леонов<br>Владимир Александрович | Татарстан Республикасы спорт министры |
| Ломакин<br>Александр Николаевич | Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрының беренче урынбасары (килешү буенча) |
| Мирзакриев<br>Рөстәм Рәүф улы | Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесе |
| Миңнегалиев<br>Роберт Хәмит улы | «Казан Экспо» конгресс-күргәзмә, мәдәни, тамаша-күңел ачу, спорт-массакүләм һәм социаль юнәлештәге чараларны үстерү һәм аларга булышлык итү үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасы генераль директоры (килешү буенча) |
| Миңнуллина<br>Талия Илгиз кызы | Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе |
| Михайлик<br>Константин Александрович | Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министры урынбасары (килешү буенча) |
| Музыченко<br>Сергей Григорьевич | Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министры урынбасары (килешү буенча) |
| Муценек<br>Юрий Петрович | Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрының статс-секретаре – урынбасары (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Нәҗмиев<br>Вәли Рифар улы | Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе башлыгы |
| Насыйбуллин<br>Назил Наил улы | Татарстан Республикасы Премьер-министрының тышкы икътисадый эшчәнлек буенча ярдәмчесе |
| Нәфыйгин<br>Альберт Илдар улы | Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесе |
| Низамов<br>Рәшит Корбангали улы | «Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча) |
| Савельев<br>Игорь Леонидович | Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Рәисенең Эксперт департаменты җитәкчесе |
| Сәлимгәрәев<br>Айдар Сәетгәрәй улы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе |
| Сафин<br>Ленар Ринат улы | «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе ректоры |
| Сафиуллина<br>Динә Ринат кызы | «Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының проектлар дирекциясе» федераль автоном учреждениесе директоры (килешү буенча) |
| Сибгатуллин<br>Илдар Нурзадә улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Төзелеш, транспорт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыклары идарәсе башлыгы |

| | |
|---|---|
| Стасишин<br>Никита Евгеньевич | Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министры урынбасары (килешү буенча) |
| Шакиров<br>Рафар Мирзанур улы | «Төзелеш һәм архитектура буенча Татарстан Республикасының дәүләт экспертизасы һәм бәяләр кую идарәсе» дәүләт автоном учреждениесе директоры (килешү буенча) |
| Шумаков<br>Николай Иванович | «Россия архитекторлары берлеге» гомумроссия иҗади һөнәри иҗтимагый оешмасы президенты (килешү буенча) |

___________